# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге Баганалы урман хуҗалыгы авыл торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2022 елның 13 октябреннән** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 12 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Баганалы урман хуҗалыгы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту;

2) авылларда урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарлары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 9 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 9 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 9 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлегендәге Баганалы урман хуҗалыгы авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Майна авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Баганалы урман хуҗалыгы авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокллы

хезмәткә алынучы гражданнардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту;

2) авылларда урамнарны яктыртуны карап тоту (урам фонарлары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен,Майна авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә,Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Майна авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручыга Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Майна авыл җирлеге башлыгы
Вазыйфаларын башкаручы В.В. Горбунов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ